*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА
**БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге иренләшкән сузык авазларның санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Коега төкермә, суын үзең эчәрсең*. (Мәкаль)
а) 2
ә) 4
б) 5
в) 6

2. Ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
а) урман
ә) сөлге
б) унбиш
в) урманнар

3. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрнең барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Кайда су чыкса, коены шунда казыйлар*. (Мәкаль)
а) кайда
ә) казыйлар
б) кайда, казыйлар
в) кайда, шунда, казыйлар

4. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
***коры елгага батыру***
а) алдалау
ә) ачулану
б) тавышлану
в) көлү

5. ***Зәңгәр*** сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
а) зәңгәр күлмәк
ә) зәңгәр һава
б) зәңгәр чәчәк
в) зәңгәр хыял

6. Тамырдаш булмаган сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
а) юлдаш, юлчы
ә) башлы, башлык
б) аклык, аклама
в) белән, белде

7. Билгесезлек алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) минеке
ә) шул
б) кемдер
в) беркем

8. Чикләүне белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**

а) гына
ә) ич
б) түгел
в) дөм

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Тирән күлдә балык та* ***күбрәк****.* (Мәкаль)

а) ия
ә) хәбәр
б) күләм хәле
в) аергыч

10. Инкяр җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Суның кадере чишмә корыгач беленә. (Мәкаль)
ә) Тамчыдан күл җыела. (Мәкаль)
б) Суга батучы саламга да ябыша. (Мәкаль)
в) Суда балык адашмас. (Мәкаль)

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Бер _____________ сүзләргә басым тамгасы куелмый. Һәр иҗектә бер _____________ аваз була. Телнең лексик составын өйрәнә торган фән – _____________. Тамыр һәм сүз ясагыч кушымча – сүзнең _____________. Инфинитив – _____________ фигыль. Тиңдәш кисәкләр арасына өтер яисә _____________ куела ала.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Парлы сүзләрнең беренче компонентларын уйлап языгыз. **(4 балл)**

| | |
|---|---|
| _______-чиге | _______-белем |
| _______-төяк | _______-ярак |

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Трава пожелтела и завяла. _______________________________________________
Птицы тронулись на юг. _______________________________________________
Их гонят холод и голод. _______________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

Ямансу көзләр җитә. Урманга сары ут каба.
Яфраклар җансыз кошлар күк оча һавада.

Бакчада былбыл тына. Тып-тын яңгырлар ява.
(*Акъегет*)

2.1. Яңгыраулыкта охшашлану күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)**
_______________________________________________________________

2.2. Кече тел арты ассимиляциясе күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)**
_______________________________________________________________

2.3. Тартыклар чиратлашуы күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)**______

2.4. ***Былбыл*** сүзнең синонимын языгыз. **(1 балл)**________________________

2.5. ***Тып-тын*** сүзенә морфологик-синтаксик анализ ясагыз. **(3 балл)**
_______________________________________________________________

2.6. Җөмләгә синтаксик анализ ясагыз (җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә языгыз). **(5 балл)**

***Яфраклар җансыз кошлар күк оча һавада.***
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

3. **«Быелгы көз»** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________